КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь г.Казань № 1658

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче карары белән расланган Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 861 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен үткәрү һәм сайлау турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү куркынычын бәяләү максатларында мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары билгеләнә:

яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән шундый ук чорда сатылган дару препаратлары санын саклаганда яки аның артуы 5 проценттан артмаганда алдагы календарь ел белән чагыштырганда календарь ел өчен яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын сатудан тулаем табышны ике тапкырга һәм аннан да күбрәк тапкырга арттыру.»;

13 пунктта «куркыныч индикаторлары» сүзләрен «куркыныч индикаторы» сүзләренә алмаштырырга;

45 пунктның дүртенче абзацында «куркыныч индикаторлары» сүзләрен «куркыныч индикаторы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин